ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пунктында гражданнардан узара салым керту турында

18.03.2024 ел № 2

2003 елньң 06 октябрендәге 1Э1-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле узидарә турында» Татарстан Республикасы Законыныц 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 1 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сөендек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 08.12.2023 елгы 1 номерлы, “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл жирлеге Сөендек торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” 08.12.2023 елгы 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сөендек торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сөендек авылы гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сөендек авыл җирлегенең Сөендек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 08.12.2023 елгы № 1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сөендек авыл җирлегенең Сөендек торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 08.12.2023 елгы № 2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сез 2024 елда Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сөендек торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктырту лампаларын һәм запас частьләрне (фотореле, клипслар, чыбыклар һәм

башка кирәкле комплект детальләрен) сатып алу, урам яктырту лампаларын алыштыру буенча электр хезмәтләре өчен түләү);

- Сөендек торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәте өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

- Сөендек торак пункт территориясен төзекләндерү (үләнне механикалаштырылган чаптыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Сөендек торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (тракторчының карны механикалаштырылган җыештыру буенча хезмәт күрсәтүләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу хезмәтләре);

- Сөендек торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, традицион рәвештә күмү урыннарын төзекләндерү (каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, традицион каберлекләр урынында каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, Сөендек авылындагы зиратны коймалау өчен материаллар сатып алу)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 108 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 69.

Тавыш бирү нәтижәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә буленде:

«РИЗА» позициясе өчен - 69, «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүче юк.»

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл жирлеге мәгълүмати стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сарлы авыл җирлеге башлыгы
Азнакай муниципаль районы И.М. Камалетдинов